**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

чираттан тыш утырыш
# КАРАРЫ

20 гыйнвар 2020 ел **№ 225** Теләче авылы

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советы аппараты турында» 2006 елның 17 февралендәге 31 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау һәм аның хезмәткәрләренең иң чик санын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советының 2013 елның 28 октябрендәге 170 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 гыйнварындагы тәкъдимен, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесенең 2020 елның 14 гыйнварындагы 11-300 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте**:

1.«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының структурасын раслау һәм аның хезмәткәрләренең иң чик санын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советының 2013 елның 28 октябрендәге 170 номерлы карарына (2013 елның 19 декабрендәге 188 номерлы, 2014 елның 26 маендагы 212 номерлы, 2014 елның 27 ноябрендәге 234 номерлы, 2015 елның 17 апрелендәге 263 номерлы, 2016 елның 22 апрелендәге 47 номерлы, 2018 елның 12 апрелендәге 128 номерлы, 2018 елның 24 августындагы 142 номерлы, 2019 елның 28 мартындагы 172 номерлы, 2019 елның 21 августындагы 186 номерлы, 2019 елның 18 сентябрендәге 193 номерлы, 2019 елның 20 ноябрендәге 208 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасыннан Башкарма комитет Җитәкчесенең ярдәмчесе (мобилизацион эш буенча) муниципаль хезмәт вазыйфасын чыгарырга:

1.2. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

хезмәткәрләренең иң чик санын 34 штат берәмлеге күләмендә билгеләргә.».

1.3. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын кушымта нигезендә расларга.

2.Теләче муниципаль район Советы аппаратына түбәндәге муниципаль хезмәт вазыйфасын кертергә: Теләче муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе (мобилизацион эш буенча).

2.1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советы хезмәткәрләренең иң чик санын 10 штат берәмлеге күләмендә билгеләргә.

2.2.«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советы аппараты турында» 2006 елның 17 февралендәге 31 номерлы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советы карарына (2012 елның 10 августындагы 118 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3. Теләче муниципаль районының 2006 елның 17 февралендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советы аппараты турында Нигезләмәнең 1.6 пунктына түбәндәге редакциядә, әлеге үзгәрешләрне кертергә:

«1.6. Аппарат составына түбәндәгеләр керә:

- Теләче муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе;
- Теләче муниципаль районы Башлыгының ярдәмчесе (Теләче муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча);
- Теләче муниципаль районы Башлыгының ярдәмчесе (мобилизацион эш буенча);
- оештыру бүлеге;
- гомуми бүлек.

Теләче муниципаль районы Советы карары белән җирле үзидарә органнарының аерым бурычларын, вәкаләтләрен үтәү өчен башка структур бүлекчәләртөзелә. Кирәкле очракларда структур бүлекчәләрнең исемлеге үзгәрергә мөмкин.».

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының законлылыкны, хокук тәртибен һәм депутат этикасын үтәү комитетына йөкләргә.

Теләче муниципаль районы
Башлыгы урынбасары А.Г. Фәтхуллин